ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫ£
ЭТИЛ СПИРТЫ һ¥М АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ¡ИТЕШТЕРҮНЕ,
¥ЙЛ¥НЕШТ¥ ЙЇРТҮНЕ,
СЫЙФАТЫН Д¥ҮЛ¥Т ТИКШЕРҮЕН
Т¥ЭМИН ИТҮ һ¥М КУЛЛАНУЧЫЛАР
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
Д¥ҮЛ¥Т ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дѢҮлѢт алкоголь инспекциясе)

---

# БОЕРЫК

24.02.2016 № 12–07 / 17

Казан ш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибен раслау хакында

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Федераль дәүләт хезмәтенең аерым дәүләти вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 10 октябрь, 2015 ел, № 506 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына билгеләү һәм вазыйфадан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан хәл ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 12 гыйнвар, 2016 ел, № УП-5 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибен (алга таба - Тәртип) (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар бүлегенә (Галкина В.В.) Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең дәүләти гражданлык хезмәткәрләрен бу боерык белән таныштырырга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең хокук бүлегенә (Эйдинов Б.Г.) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәүгә алуны тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **И.А.Марченко**

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь инспекциясенең
24 февраль, 2016 ел, № 12/07-17
боерыгына кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибе**

1. Бу Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәре) тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни исемнәрдән тыш), бүләкләрен (алга таба – исемнәр, бүләкләр), гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи бурычларына әлеге оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү кергән очракта, алу тәртибе билгеләнә.

2. Гражданлык хезмәткәре исемнәр, бүләкләр алганда Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесеннән (алга таба – җитәкче) рөхсәт алырга тиеш.

3. Исем, бүләк алган яки чит ил дәүләте, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмә тарафыннан исем яки бүләк бирелү турында хәбәр алган гражданлык хезмәткәре өч эш көне эчендә кадлар бүлегенә чит ил дәүләтенең, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен, бүләген алуга рөхсәт бирү турында бу Тәртипкә № 1 кушымта нигезендә төзелгән үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) тапшыра.

Үтенечнамәне карап тикшерү срогы бу Тәртипнең 8 пункты нигезендә кадрлар бүлегендә үтенечнамә теркәүгә алынганнан соң ун эш көне тәшкил итә.

4. Исемнән, бүләктән баш тарткан гражданлык хезмәткәре өч эш көне эчендә кадрлар бүлегенә чит ил дәүләтенең, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең мактаулы һәм махсус исемен, бүләген алудан баш тарту турында бу Тәртипнең № 2 кушымтасында күрсәтелгән формада тутырылган уведомление (алга таба – уведомление) тапшыра.

5. Исем, бүләк алган гражданлык хезмәткәре үтенечнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җитәкче тарафыннан карар кабул ителгәнче, исемгә документларның төп нөсхәләрен һәм бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен, аларны алганнан соң өч эш көне эчендә, кадрлар бүлегенә саклауга тапшыра. Шул ук вакытта бу Тәртипкә № 3 кушымта нигезендәге форма буенча кабул итеп алу-тапшыру акты төзелә.

6. Гражданлык хезмәткәре хезмәт командировкасы вакытында исем, бүләк алганда яки алардан баш тарткан очракта, үтенечнамә яки уведомление тапшыру срогы гражданлык хезмәткәре хезмәт командировкасыннан кайткан көннән башлап

исәпләнелә.

7. Гражданлык хезмәткәре үзенә бәйсез сәбәп аркасында бу Тәртипнең 3-5 пунктларында күрсәтелгән срокларда тапшыра алмаган очракта, үтенечнамәне яки уведомлениене, исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен мондый сәбәп юкка чыгарылганнан соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

8. Үтенечнамәне (уведомление) теркәү кадрлар бүлеге тарафыннан, кабул итеп алынган көнне бу Тәртипкә № 4 кушымта нигезендә төзелгән теркәү журналында хәл ителә. Кадрлар бүлеге ике эш көне эчендә теркәлгән үтенечнамәне (уведомление) җитәкчегә карап тикшерүгә җибәрә.

9. Кадрлар бүлеге ике эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә үтенечнамәне (уведомлениене) карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җитәкче тарафыннан кабул ителгән карар турында хәбәр итә һәм аңа, җитәкче резолюциясе белән, үтенечнамәнең (уведомление) күчермәсен (кадрлар бүлеге мөһере белән расланган), имза салдырып, тапшыра. Җитәкче резолюциясе белән үтенечнамәнең төп нөсхәсе (уведомление) гражданлык хезмәткәренең личное делосына куела.

10. Кадрлар бүлеге, җитәкче бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән гражданлык хезмәткәре үтенечнамәсен канәгатьләндергән очракта, 10 эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә исемгә документларны төп нөсхәләрен, бүләк һәм аңа документларның төп нөсхәләрен тапшыра. Шул ук вакытта бу Тәртипнең № 3 кушымтасы нигезендә кабул итеп алу-тапшыру акты төзелә.

11. Кадрлар бүлеге, җитәкче бу Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән гражданлык хезмәткәре үтенечнамәсен канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, 10 эш көне эчендә исемгә документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа документларның төп нөсхәләрен чит ил дәүләтенең, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең тиешле органына җибәрә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти граждsuccessful хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибенә №1 кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенә

____________________________________
(вазыйфасы атамасы)

______________________________ дән

_________________________________
(Ф.И.О., телефон номеры)

Чит ил дәүләтенең, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә һәм дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исемен, бүләген алуга рөхсәт бирү турында

үтенечнамә

Миңа кабул итүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм_____________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исем, бүләк атамасы)

__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
(нинди хезмәтләр өчен исем бирелгән һәм карафыннан бирелгән, нинди хезмәтләр өчен бүләкләнгән һәм кем тарафыннан)

______________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемгә,бүләккә документлар тапшыру датасы һәм урыны)

Мактаулы яки махсус исемгә документлар, бүләк һәм аңа документлар
(кирәклесенең астына сызарга)

_________________________________________________________________________
________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исем, бүләк атамасы)

_______________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемгә, бүләккә документлар атамасы)

кабул итеп алу-тапшыру акты буенча Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар бүлегенә тапшырылган № _____ «____»______20__ел

« ____ »_________ 20 ____ ел _____________ ________________ ________
(имза) (фамилиясе һәм иниц.)

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти граждамнлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибенә №2 кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенә

_________________________________________

______________________________________ дән

(вазыйфасы атамасы)

___________________________________________

(Ф.И.О., телефон номеры)

Чит ил дәүләтенең, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини берләшмәнең мактаулы яки махсус исеменнән, бүләгеннән баш тарту турында

Уведомление

… алудан баш тарту турында карар кабул итемне җиткерәм ________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(мактаулы яки махсус исем, бүләк атамасы)

_______________________________________________________________________________

(нинди хезмәтләр өчен исем бирелгән һәм тарафыннан бирелгән, нинди хезмәтләр өчен бүләкләнгән һәм кем тарафыннан)

« _____ »__________ 20 _____ ел ______________ _ ___________________________

(имза) (фамилиясе һәм инициал.)

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти граждандык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибенә №3 кушымта

Кабул итеп алу-тапшыру акты

“__”_________20_ел №__________

Без, түбәндә кул куючылар, түбәндәге турында акт төзедек____________________________________________________

(Ф.И.О.)

_____________________________________________________________

(вазыйфасы)

тапшырды/кабул итте (кирәклесенең астына сызарга), ә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар бүлеге начальнигы

_____________________________________________________________

(Ф.И.О., вазыйфасы)

түбәндәгеләрне кабул итте/тапшырды:

| № п/п | Атамасы | Саны(данә) | Тасвирламасы |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тапшырды: Кабул итте:

_______ ____________________ ______________ __________

(имзасы) (тулы имзасы) (имзасы) (тулы имзасы)

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит ил дәүләтләренең, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен алу тәртибенә №4 кушымта

# Үтенечнамәләрнең (уведомлениеләр) учетын алып бару өчен ЖУРНАЛ

| № п/п | Үтенечнамә (уведомление) тапшырган гражданлык хезмәткәренең Ф.И.О. | Үтенечнамә (уведомление) тапшырган гражданлык хезмәткәренең вазыйфасы | Үтенечнамәнең (уведомление) алыну датасы | Бүләк, исем атамасы | Кабул итү-тапшыру акты (булганда) реквизитлары | Үтенечнамәне (уведомление) кабул итеп алган затның имзасы, Ф.И.О. | Үтенечнамә (уведомление) тапшырган затның имзасы, Ф.И.О. | Җитәкченең карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |